МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.07.2017 г. Казань № 603 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны тикшерү, эшкәртү һәм кабул итү тәртибен раслау турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә дәүләт гражданнар хезмәте турында»гы Федераль законның № 79-ФЗ ның 20.2 маддәсе, Татарстан Республикасының 2003 елның 16 гыйнварында кабул ителгән “Татарстан Республикасында дәүләт гражданнар хезмәте турында”гы № 3-ЗРТның 17.2 маддәсе нигезендә БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны тикшерү, эшкәртү һәм кабул итүнең тәкъдим ителгән Тәртибен расларга.

2. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
мәдәният министрының
25.07.2017 № 603 од
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны тикшерү, эшкәртү һәм кабул итүнең тәртибе

I. Гомум нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны тикшерү, эшкәртү һәм кабул итүнең тәртибе (алга таба - Тәртип) түбәндәгеләрне билгели:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар (алга таба - гражданин) һәм Татарстан Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны тәкъдим итү тәртибе:

Сайтлар турындагы Мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе;

Сайтлар турындагы Мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе.

2. 2006 елның 27 июлендә кабул ителгән № 149-ФЗ “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында”гы Федераль законның 7 маддәсенең 1 нче өлеше нигезендә һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар дигәндә һәркем карый алган гомуммәгълүм белешмәләр һәм башка мәгълүмат күздә тотыла. Шул ук вакытта мәгълүматтан файдалануда чикләүләр булмау чикләнмәгән күләмдәге кешеләргә гражданлык хезмәткәре яки граждан ризалыгын алмыйча урнаштырылган мәгълүматны алу һәм файдалану мөмкинлеге бирә.

3. Гражданлык хезмәткәре яки гражданның шәхесен ачыкларга мөмкинлек бирүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматларның берсе булырга мөмкин: исем-фамилиясе, фотосурәте, эш урыны.

## II. Сайтлар турындагы мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү

4. Сайтлар турындагы мәгълүматлар түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

граждан – Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) алынган вакытта гражданлык хезмәтенә алынганчы өч календарь ел өчен;

гражданлык хезмәткәре – календарь ел алдыннан килгән хисап елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча;

5. Сайтлар турындагы мәгълүмат гражданнар һәм гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тәкъдим ителә (алга таба – форма).

6. Гражданлык хезмәткәренең вазифаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган очракта һәркем күрә алган мәгълүмат Формада чагылыш табарга тиеш түгел.

7. Тутырылган форма Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән сайтлар турындагы Мәгълүматларны эшкәртү өчен җаваплы итеп билгеләнгән кадрлар бүлеге хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) гражданлык хезмәткәре яки граждан тарафыннан тәкъдим ителә.

8. Җаваплы зат Форманы тутыруның тулылыгын, "Интернет" челтәреннән файдаланып анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, үзенең имзасын куя, Форма алынган көндә бу Тәртипкә Кушымта нигезендә форма буенча журналга белешмәләр кертә.

9. Тутырылмый калган җирләре булган форма кабул ителми.

10. Граждан тәкъдим иткән формада дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар булган очракта, кадрлар бүлеге шунда ук гражданлык хезмәтенә вазифага билгеләүдән баш тарту турында хәбәр итә.

11. Сайтлар турындагы мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан "Татарстан Республикасында һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәттә дәүләт гражданлык хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында гражданлык хезмәткәрләренең шәхси карточкаларына кертелә.

12. Гражданлык хезмәткәрләре һәм гражданнар тәкъдим иткән формалар биш ел дәвамында кадрлар бүлегендә саклана, аннары Министрлыкта шәхси мәгълүматларны эшкәртү Кагыйдәләре белән расланган тәртиптә юкка чыгарыла.

## III. Сайтлар турындагы Мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Гражданлык хезмәткәрләре тәкъдим иткән сайтлар турындагы Мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү министр (министр вазифаларын башкаручы зат) боерыгы буенча башкарыла (алга таба - министр).

14. Тикшерү өчен нигез булып түбәндәге органнар тарафыннан язма рәвештә бирелгән мәгълүмат санала:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары

һәм аларның вазифаи затлары;

сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкчелек органнары һәм закон нигезендә теркәлгән сәяси партияләр саналмаган башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләр;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат язма формада тикшерү үткәрү турындагы боерык басылганнан соң ике көн дәвамында гражданлык хезмәткәренә аңа карата тикшерү башлану турында хәбәр итә.

16. Гражданлык хезмәткәре тәкъдим иткән сайтлар турындагы Мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне җаваплы зат “Интернет” челтәрендә һәркем күрә алган мәгълүмат урнаштыру һәм күрсәтелгән мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотлар) булдыру рәвешендә башкара.

17. Гражданлык хезмәткәре тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәләре буенча язма формада аңлатма бирә, өстәмә материаллар тәкъдим итә ала.

18. Бу Тәртипнең 17 нче пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына өстәлә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүмат тикшерү үткәрү турында боерык басылганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча министрга тәкъдим ителә.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көн эчендә министр түбәндәге карарларны кабул итә:

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык куллану өчен нигез булмау турында;

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык куллану турында;

хокук бозу, җинаять, экстремистлык эшчәнлеге билгеләре булган вакытта тикшерү материалларын дәүләт органнарына юллау турында.

21. Министр кабул иткән карар турында җаваплы зат ике эш көне дәвамында тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә язмача хәбәр юллый.

22. Министрның язма рөхсәте белән сайтлар турындагы мәгълүматлар бер үк вакытта тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә хәбәр ителеп, Россия Федерациясенең шәхси мәгълүматлар һәм дәүләт сере турындагы законнарын үтәп, хокук саклау органнары, даими эшли торган сәяси партияләрнең җитәкчелек органнарына, закон нигезендә теркәлгән сәяси партияләр саналмаган гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләренә, тикшерү үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат тәкъдим иткән гомумроссия һәм республика мәгълүмат чараларына да тәкъдим ителә ала.

23. Тикшерү материаллары, ул тәмамлангач, өч ел дәвамында кадрлар бүлегендә саклана, аннары архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турындагы мәгълүматларны тәкъдим итмәгән өчен җаваплылык

24. Сайтлар турындагы Мәгълүматны тәкъдим итмәгән очракта гражданин гражданлык хезмәтенә кабул ителми, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтендә була алмый.

25. Гражданлык хезмәткәренең сайтлар турындагы Мәгълүматларны тәкъдим итмәве гражданлык хезмәтеннән азат итүне таләп итүче хокук бозу санала.

–

Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларына дәгъва кылучы гражданнар (алга таба - гражданин) һәм Татарстан Мәдәният министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан һәркемгә аңлаешлы мәгълүматлар, шулай ук аларны тиңләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайт адреслары һәм (яки) сайт сәхифәләре хакындагы мәгълүматларны исәпкә алу журналы

| № п/п | Дата представления/приема формы | Форманы тәкъдим итүченең исем-фамилиясе | Форманы тәкъдим итүченең вазифасы (граждан дәгъва иткән вазифа) | Форманы тәкъдим итүченең имзасы (форма почта аша алынган очракта № вх.) | Форманы кабул итүченең исем-фамилиясе | Форманы кабул иткән затның имзасы | Информация о проверке (реквизиты приказа, результат проверки) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |